СОВЕТ
ПЕТРОПАВЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 33
с.Слобода Петропавловская,423198

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПЕТРОПАВЕЛ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин урамы, 33
Петропавловка бистәсе авылы, 423198

тел.: (8-4348) 3-35-41, факс: (8-4348) 3-35-18.Ppav.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Петропавел авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 26 марты № 9-25

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендә кабул ителгән 34-96 номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 146-ФЗ номерлы Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендә кабул ителгән 34-96 номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына (2015 елның 11сентябрендәге 44-131 номерлы, 2015 елның 2 ноябрендәге 4-9 номерлы, 2018 елның 14 ноябрендәге 41-116 номерлы, 2019 елның 23 сентябрендәге 50-140 номерлы карарлар редакциясендә) киләсе үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкаларын киләсе күләмдә билгеләргә:

1) шул исәптән әлеге пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарына;
мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан корылмаларга яки хуҗалык корылмаларына карата 0,1 процент;

2) фатирларга,
фатир өлешләренә,
бүлмәләргә карата 0,2 процент;

3) торак йортларга,
торак йортларның бер өлешләренә;
төзелеп бетмәгән объектларга, әгәр мондый объектларның проектлаштырыла торган билгеләнеше торак йорт булса;
составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплексларга карата0,3 процент;

4) әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына, әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектларына, шулай ук салым

салу объектларына карата, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2 процент;

5) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.».

1.2. 4 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайланган салым салу объекты турында хәбәрнамә салым органы тарафыннан алынганнан соң 30 көн эчендә карала. Салым органы Салым кодексының 85 статьясындагы 13 пункты нигезендә запрос җибәргән очракта, салым органының Җитәкчесе (Җитәкче урынбасары), салым түләүчегә хәбәр итеп, мондый хәбәрнамәне карау вакытын 30 көннән дә артык вакытка озайтырга хокуклы.».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" бастырырга .pravo.tatarstan.ru) һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (novosheshminsk.tatarstan.ru.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Петропавел авыл җирлеге башлыгы

Д.С.Никитин